| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ул.Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330 | Ленин ур., 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330 |

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 27 » июнь 2023 ел № 20

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 18 гыйнварындагы 01 номерлы «Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Радужная урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (22.02.2023 №06, 27.04.2023 №15 карарлар редакциясендә)

Азнакай шәһәренең Радужная урамындагы 3 нче йорт адресы буенча урнашкан, күпсанлы җитешсезлекләре булган йортта озак вакыт яшәргә мәҗбүр булган гражданнарның тормыш һәм сәламәтлек иминлеген кайгырту йөзеннән, күпфатирлы йортта яшәүчеләрне авария хәлендәге һәм җимерелергә тиешле йорттан торакчыларны күчерү карарын тизләтү максатыннан, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 18 гыйнварындагы 01 номерлы «Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Азнакай шәһәре, Радужная урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турында» карарына (22.02.2023 №06, 27.04.2023 №15 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Радужная урамындагы 3 нче йортның милекчеләренә авария хәлендәге йортны сүтүне яки реконструкцияләүне таләп иткәннән соң өч ай эчендә авария хәлендәге йортны җимерүне тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 18 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.А.Габдрахманов